**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл жирлеге составына керүче Иске Җирекле авылында гражданнар жыены нәтижәләре турында**
**КАРАР**

28 ноябрь. 2021 ел № 1

«Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1. 56 статьялары. «Татарстан Республикасында жирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 27 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар жыены нәтижәләре белән гражданнар жыены беркетмәсе төзелде:

«2022 елда яшәү урыны буенча Мәләкәс авыл жирлеге Иске Җирекле авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 (бер мең) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары. ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар. күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 500 (биш йөз) сум күләмендә билгеләргә. әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

-янгын сүндерү машинасы өчен гаражны төзекләндерү (төзелеш материаллары. жиһаз сатып алу. проект эшләре):

- юлларны ремонтлау;

- урам яктырткычлары өчен электр материалларын сатып алу һәм урнаштыру;

- видеокүзәтү сатып алу һәм урнаштыру (Иске Җирекле авылында ТАССРның 100 еллыгы паркы);

-Катков урамында су үткәргечне төзекләндерү (монтаж. урнаштыру. су үткәргеч торбалар сатып алу һәм махсус техника хезмәтләре

ӘЙЕ ЮК».

Гражданнар жыены нәтижәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия жыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар жыенында катнашучы 1489 кеше кертелде. тавыш бирүдә катнашкан гражданнар жыенында катнашучылар саны – 794 кеше.

Тавыш бирү нәтижәләре буенча жыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар жыенында катнашучы 791 кеше тавыш бирде:

«Юк» позициясе өчен жыенында катнашучы 3 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар жыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл жирлеге Иске Җирекле авылында гражданнар жыенын узган. гражданнар жыены нәтижәләрен гамәлдә дип танырга.

2. «2022 елда яшәү урыны буенча Мәләкәс авыл жирлеге Иске Җирекле авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 (бер мен) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 500 (биш йөз) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

-янгын сүндерү машинасы өчен гаражны төзекләндерү (төзелеш материаллары, жиһаз сатып алу, проект эшләре);
- юлларны ремонтлау;
- урам яктырткычлары өчен электр материалларын сатып алу һәм урнаштыру;
- видеокүзәтү сатып алу һәм урнаштыру (Иске Җирекле авылында ТАССРнын 100 еллыгы паркы);
-Катков урамында су үткәргечне төзекләндерү (монтаж, урнаштыру, су үткәргеч торбалар сатып алу һәм махсус техника хезмәтләре)
мәсьәләсе буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл жирлеге Иске Җирекле авылы гражданнар жыены нәтижәсен авыл жирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка житкерергә.

4. Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл жирлеге Иске Җирекле авылы гражданнар жыены нәтижәсен Тукай муниципаль районынын рәсми сайтында «авыл жирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматынын рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар жыенында рәислек итүче,
Мәләкәс авыл жирлеге Башлыгы Ю.П.Васильев